ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРУССИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старые Уруссу, ул.Советская, д.16в,
423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 16в
йорт, 423960

Тел.:(85593) 4-42-31, факс:4-42-10, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 9 5 февраль 2015 ел

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 7 ноябрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 24 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 31 декабрендә ”2013 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясе Законына күчеп йөрү ирегенә, Россия Федерациясе чикләрендә булу һәм яшәү урынын сайлауга үзгәрешләр кертү турында»гы 387-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе законлы көченә керү сәбәпле һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" һәм 2015 елның 21 гыйнварындагы 02-08-01-2015 санлы Ютазы районы прокуроры протестын исәпкә алып

1. Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 7 ноябрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 24 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитетында белешмә (өземтә) бирү буенча хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентының 1 нче кушымтасында муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының 2.5 нче пунктын «муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеген» 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Яшәү урыныннан белешмә, өйдән китап өземтәләре, алдагы яшәү урыныннан белешмәләр алу өчен:

1.1. Шәхесне таныклаучы Документлар.
1.2. Йорт китабы.
1.3. Индивидуаль торак йортка хокуклар турында Документ (хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык йә индивидуаль торак йортка техник (кадастр) паспорт, йә Ростехинвентаризациядән хокук ияләре-Федераль БТИ, Татарстан Республикасы буенча филиал турында белешмә).

2.Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

2.1. Шәхесне таныклаучы Документлар.

2.2. Йорт китабы.

2.3. Сорала торган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгынраслый торган документлар (паспортлар, туу турында таныклыклар, никахлашу турында таныклыклар) кирәк.

3.Үлгән кешенең яшәү урыныннан үлгән көненә белешмә алу өчен:

3.1. Шәхесне таныклаучы Документ.

3.2. Йорт китабы.

3.3. Үлем турында таныклык (оригинал).

3.4. Сорала торган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслый торган документлар (балалар туу турында таныклыклар, никахлашу турында таныклыклар) кирәк.

4.Хуҗалык кенәгәсеннән өземтә алу өчен:

4.1. Хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү турында ирекле рәвештә гариза;

4.2. Хокук иясенең шәхесен таныклаучы документ;

4.3. Җир кишәрлегенең вафат булган хуҗасының вафат булуы турында таныклык күчермәсе;

4.4. Җир кишәрлегендә урнашкан йортка (башка объектларга, әгәр булса) хокук билгеләүче документларның күчермәләре;

4.5. Җир кишәрлегендә урнашкан йортның адрес номеры күрсәтелгән фотосурәте кирәк.

5. Физик зат вәкиле өчен мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләрне башкару вәкаләтләрен раслый торган нотариаль таныкланган документның күчермәсен тапшырырга кирәк.

6. Санап үтелгән документлар документларның тиешле оригиналлары белән бергә тапшырыла.

7. Гаризалар, документлар һәм документларның күчермәләре бер нөсхәдә тапшырыла.»

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының мәгълүмат тактасында һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайтында халыкка җиткерергә www.yutaza.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Мөхәмәтҗанова